# *Ут дус та, дошман да.

*Тәрбия сәгате*

* **Ни өчен ут дус диелгән?**

Бүгенге көндә дөньяны утсыз, газсыз күз алдына китерү мөмкин түгел. Зур-зур самолетлар күктә оча, теплоходлар суда йөзә, поезлар чаба. Өйләрдә җылы, рәхәт. Дуслар бер-берсенә ярдәм итәләр. Чыннан да ут безнең дустыбыз дип әйтә алабыз, чөнки ул безгә бик нык булыша. Бер-берең белән дус, тату яшәгәндә генә зур эшләр башкарып була, шул вакытта гына бәхетле булырга мөмкин. Р. Мингалимовның “ Дусларың гына булсын” шигыре укыла.

*Егылсаң торып була,*
*Торсаң йөгереп була,*
*Йөгерсәң җитеп була-*
*Дусларың гына булсын!*

*Сөйләшеп, уйнап була,*
*Күп нәрсә белеп була,*
*Шаярып, көлеп була-*
*Дусларың гына булсын!*

- ***Мәкаль***

“ Саклана белсәң генә ут- дус ул, игътибарсыз булсаң, дошманга әверелеп куя.”

**Укытучы**: Дошман дип нинди кешеләргә әйтәләр?

**Укытучы:** Кешегә зыян салучы, тәртипсез кешеләрне, гел начарлык эшләү турында уйлап йөрүче - көнче, явыз сугыш чукмарларын дошман диләр. Ә ут нинди очракта безнең дошманга әйләнә соң?

**Сорауларга җавап бирү:**

1. Учакны нинди урыннарда ягарга ярамый? (Коры агачлар, салам, печән кибәне, йорт янында җилле көнне)
2. Син мәктәптән кайтканда бер йорттан төтен чыкканын һәм кечкенә бала елаган тавыш ишетәсең. Син нәрсә эшләр идең?
3. Яңа ел чыршысын бизәгәндә нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?

**Куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү**:
- Әгәр дә өстендәге киемең яна башласа, җиргә ятып ауна. Телевизор яна башласа, аны су сибеп сүндермә, башта ток килү челтәреннән өз, аннары гына өстенә тыгыз одеал капла.
- Янгын була калса, беренче чиратта янгыннан чыгарга тырыш. Чыгу юллары ут эчендә булса, чыгам дип ут эченә ыргылма. Төтен белән агуланмас өчен, авызыңны, борыныңны куляулык белән томала. Һәм тәрәзә янына килеп, яисә балконга чыгып хәбәр сал. Янгыннан чыгуга **01** хезмәтенә шалтырат.
-Өйдән чыгып киткәндә, бүлмәдә ут сүнгәнме икәнен тикшер. Бервакытта да телевизорны, яисә башка электр приборларын уттан алмыйча калдырма. Аш бүлмәсендәге газ плитәсе сүнгәнме? Һәрвакытта да игътибарлы бул һәм ут белән шаярма.